**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Аю авыл җирлегенең Дружба торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**14.11.2020ел.** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде: "2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Аю торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар, БВС катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнар, 80 яшьтән өлкән пенсионерлар, күпбалалы гаиләләрдән тыш) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

1) Дружба торак пунктында зиратка койма тоту өчен материаллар салып алу;

2) Дружба торак пунктында Костин урамында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру (эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 102 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 55 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 55 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1.Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Дружба торак пунктында халык җыены узуын таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2."2021 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә (1,2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар, БВС катнашучыларның тол хатыннары, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнар, 80 яшьтән өлкән пенсионерлар, күпбалалы гаиләләрдән тыш) үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?" мәсьәләсе буенча карарны таныргa һәм түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1) Дружба торак пунктында зиратка койма тоту өчен материаллар салып алу;

2) Дружба торак пунктында Костин урамында балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру (эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

3. Аю авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru/atraklinskoye.htm) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Аю авыл җирлеге башлыгы** **А.М.Галимов**